**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 30 маендагы 2242 номерлы карары

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 23 сентябрендәге 3223 номерлы «Казан шәһәре территориясендә алкогольле продукция сату һәм җәмәгать туклануы буенча хезмәтләр күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия төзү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү кагыйдәләренең 6 пункты нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 23 сентябрендәге 3223 номерлы «Казан шәһәре территориясендә алкогольле продукция сату һәм җәмәгать туклануы буенча хезмәтләр күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия төзү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 31 мартындагы 964 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 23 сентябрендәге 3223 номерлы карарына 1 номерлы кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 30 маендагы
2242 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы буенча хезмәтләр күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган урыннар янәшәсендәге территорияләр чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Гафаров Рөстәм Гыйльфан улы | махсус комиссия рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| Шакиров Илдар Сәетҗан улы | махсус комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Әхмәтгәрәева Алсу Нәҗип кызы | махсус комиссия сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Кулланучылар базары комитетының кулланучылар базарын координацияләү бүлеге башлыгы |
| Махсус комиссия әгъзалары: | |
| Сәгыйтова Гүзәл Рәмзил кызы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Фазылҗанов Руслан Фәрит улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты рәисе |
| Гайнуллин Нияз Наил улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты рәисе урынбасары |
| Рачкова-Чукина Татьяна Саидовна | Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты рәисе урынбасары – хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| Шәмсетдинов Ренат Харрас улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы |
| Салихов Альберт Иршат улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы |
| Жаворонков Владимир Владимирович | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы |
| Фәтхетдинов Роман Рәмиз улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы |
| Ризванов Ирек Асаф улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы |
| Әхмәтшина Екатерина Наил кызы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгының беренче урынбасары |
| Филатов Владимир Сергеевич | Казан шәһәренең Сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Егорова Марина Ивановна | Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы башлыгы (килешү буенча) |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче кызыксынучы физик затларның вәкилләре | (килешү буенча) |
| Мәдәният, мәгариф һәм сәламәтлек саклау оешмалары вәкилләре | (килешү буенча) |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар | (килешү буенча) |